**Сүз ясалышы ысуллары** дип телнең үз чаралары ярдәмендә яңа сүзләр ясау юлларын, алымнарын атыйлар

# Сүз ясалышы ысуллары:

-сүз ясагыч кушымча ялгану;

- сүзләр кушылу;

- фонетик ысул;

- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү;

- сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү;

- сүзләрне кыскарту.

# Тема:

# Сүз ясалышы.Сүзләрне кушу ысулы.Кабатлау.

# 26нчы апрель-бөек шагыйребез Габдулла Тукай туган көн



# Сүзләр кушылу ысулы

Кушма

Парлы

Тезмә

# Кушма сүзләр

Ике яки берничә сүздән кушылып ясала

Һәм яңа бер мәгънә белдерә.Алар һәрвакыт кушылып языла.

# Кушма сүзләр ясарга,алар белән җөмләләр төзергә

**1нче төркем**

**ак**

**туй**

**боек**

**күмер**

**2 нче төркем**

**җимеш**

**агач**

**яулык**

**Идел**

# Унсигезенче апрель.
# Сүзләр кушылу ысулы.
# Кабатлау.


АККОШ





# Сабантуй







төнбоек


ташкүмер


ГӨЛҖИМЕШ


АЛМАГАЧ


КУЛЪЯУЛЫК


АГЫЙДЕЛ

# Парлы сүзләр

**Үзара синоним, антоним мәгънәле яки аваздаш сүзләрдән төзелә һәм сызыкча аша языла**

# Тезмә сүзләр

**Тезмә сүзләр ике яки берничә сүздән тезелеп ясала, бербөтен мәгънәне белдерә.Бер сорауга җавап бирә, бер җөмлә кисәге була.Һәр сүз аерым языла. Тезмә сүз составындагы сүзләрне аерып карарга ярамый.**

# Тезмә сүзләрне һәм сүзтезмәләрне ике баганага аерып язарга.

**Тимер юл, тимер таяк, каен җиләге, каен сыну, чәчәк ату, чәчәк җыйды, Бөек Ватан сугышы, бөек кешеләр, Хезмәт Герое, хезмәт дәресе.**

| Тезмә сүз | Сүзтезмә |
| --- | --- |
| тимер юл | тимер таяк |
| каен җиләге | каен сыну |
| чәчәк ату | чәчәк җыйды |
| Бөек Ватан сугышы | бөек кешеләр |
| Хезмәт Герое | хезмәт дәресе |

**Барлык төрки һәм шәрекъ дөньясындагы татарлар өчен Тукайның ни*кадәр кадерле булуын әйтеп бирерлек сүзләр юктыр, мөгаен. Аның шигърияте ндә халкыбызның җаны*рухы чагыла, ә милләт рухы, мәгълүм булганча, бер*кайчан да үлми һәм бизмәннәрдә үлчәнми. Димәк, Габдулла Тукайның да иҗаты үлемсез һәм иксез*чиксез, ул татар мәдәниятенең үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән аерылгысыз.**

*Минтимер Шәймиев.Тукай турында.*

- *Шәрекъ-көнчыгыш*
- *Бизмән-үлчәү*

# Тест

**1.Тезмә сүзләр күрсәтелгән рәтне билгеләгез.**

а)ара(тирә), аш(су), хатын(кыз)
ә)тар(юл),зур (агач),мәктәп (бакчасы)
б)җир(җиләге), ял(ит),туган(ил)

**2.Кайсы рәттә парлы сүзләр бирелгән?**

а)төн(боек),өч(аяк),ис(киткеч)
ә)ата(ана),кием(салым), бала(чага)
б) юл(чы), утын(лык), оял(чан)

**3. Кушма сүзләр күрсәтелгән рәтне билгеләгез.**

а)кул(яулык), тере(көмеш), таш(күмер)
ә)ак(кар),җылы(җәй),биек(тау)
б)туган( көн), очкылык (тоту), бал (корты)

# Өйгә эш.

**Кушма, парлы, тезмә сүзләр кергән мәкальләр язып килергә.**